Бөтендөнья татар конгрессы

# Татарлар: гамәл стратегиясе

# ТАТАРЛАР: ГАМӘЛ СТРАТЕГИЯСЕ

«Татар булмасаң, кем син?» – дип мөрәҗәгать итә Шиһабетдин Мәрҗани милләттәшләренә XIX гасырның икенче яртысында. Аның артыннан ук, XX гасыр башында Гаяз Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә замандашларын татар халкына ике гасырдан бөтенләй юкка чыгу куркынычы янавы турында кисәтә. Бу – карусыз көрәшчелек түгел, иҗтимагый үзгәреш шартларында татарларны уйланырга, үз халкы хакына аңлы гамәлләр кылуга өндәү теләге.

Татарларга һәрвакыт үз-үзләрен танып белүгә омтылыш хас булган, бу – үсеш юлларын билгеләүнең бер ысулы. Фикер ачыклыгы хак юлдан тайпылмаска, хәрәкәт юнәлешен төгәл күзалларга ярдәм итә. Йөз еллар элек тә шулай булган һәм хәзер дә - яңа дөньякүләм үзгәрешләр, кешелекнең тизләнешле үсеше чорында да шулай булып кала.

Бүгенге көндә татарлар – Россия Федерациясендә сан ягыннан икенче урында торучы халык. Җир шарында барлыгы сигез миллионга якын татар яши. Ләкин, тарихтан күренгәнчә, күпсанлы булу гына дөнья күләмендә уңышка ирешүне тәэмин итә алмый. Үз халкының рухи хәзинәләрен аңлы рәвештә кабул итмәсәләр, аның киләчәгенә омтылмасалар, татарлар «милләт» графасында рәсми билге генә булып калырга мөмкин.

Иң мөһим сорау - кем соң ул хәзерге татар кешесе? Дөньяга һәм кешелеккә әйтер сүзе бармы аның? Татарлар бу дөньяны яхшыртырдай идеяләр тудыра аламы? Заман таләпләрен үтәргә әзерме? Россиянең һәм дөньяның чиксез киңлекләренә таралып яшәсәләр дә, үзләрен олы татар гаиләсенең бер өлеше дип санаучы миллионлаган, беренче карашка төрле-төрле кебек күренгән кешеләрне нәрсә берләштерә?

***

Татар милли мәдәнияте тарихи үткәнне чагылдыра һәм халыкның хәзерге асылын билгели, ә үткәндә һәм бүгенгедә аның киләчәк рәвешләре һәм мәгънәләре шытып чыга. Мәдәният халкыбызның тиңсез мирасын - гореф-гадәтләрен һәм йолаларын, телен, акыл һәм сәнгать иҗаты үрнәкләрен берләштерә. Бу хәзинә, һәрдаим яңартылып, киләсе буыннарга тапшырыла килә. Татар мәдәниятенең үзенчәлеге - аның дөньяга ачык булуы, башка халыклар мәдәниятләре белән үзара ярашып, «гадәт вә әхлак алмашып» үсүе.

Татарларның милли мәдәнияте милли үзаңнан башка яши алмый, ә милли үзаң исә үз халкыңның тамырларын һәм рухи хәзинәләрен аңлы рәвештә кабул итүдән ярала.

Татарларда тарихи һәм мәдәни процесслар иҗтиһадның ныклы нигезенә корыла. Хунну мәмләкәте, һуннар берлеге, төрки каһанлыклар,

Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, урта гасыр ханлыклары заманнарыннан алып татарларның ата-бабалары дәүләтләр һәм бөек шәһәрләр төзегән, сәүдә юллары салган, төрки-татар цивилизациясенең рухи һәм сәнгати мәдәниятенең күренекле үрнәкләрен иҗат иткән. Хәзерге татарларның нәсел тамырлары барып тоташкан халыкларның ике мең елга якын язма тарихы бар. Ата-бабалар казанышларын өйрәнү яшьләрдә дөньяга киң караш тәрбияли һәм яңа буыннарны иҗади хезмәткә рухландыра.

Татарлар гомер-гомергә Көнчыгышта – көнбатыш дөньяның, ә Көнбатышта Көнчыгышның бер өлеше булып торган. Алар зур-зур тел гаиләләренең һәм дөнья диннәренең үзара актив бәйләнышлары тирәлегендә яшәгәннәр, әлеге цивилизацияләрнең һәркайсының табигый бер өлеше дә, аларның үзара диалогында тоташтыручы буын да булып торганнар.

Татар мәдәнияте үзара хезмәттәшлеккә сәләтен Төньяк Евразиянең байтак җирләре Россия дәүләте составына кергәч күрсәткән. Хәзерге Россия җәмгыяте оешуда заман җәмгыятен барлыкка китерүдә татар мәдәниятенең мөһим тарихи роль уйнаганлыгы бүген ачык аңлашыла.

Татарларның Россия дәүләте хезмәтендә Ватанны ныгытуга керткән өлеше гаять зур. Күп кенә хәрби җитәкчеләрнең, дәүләт эшлеклеләренең, галимнәрнең һәм зыялыларның нәселләрендә

татарлар булган. Милләттәшләребез бүген дә, кешелек алдында торучы дөньякүләм мәсьәләләрне хәл итүгә үз өлешләрен кертеп, Россия Федерациясе икътисадының төрле өлкәләрендә, дөньяның төрле почмакларында уңышлы эшлиләр.

Татар халкының XX гасырдагы үсешендә милли дәүләт автономиясе төзелү аерым урын алып тора. ТАССР төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтүче Татарстан Республикасы икътисад, мәдәният, инновацияләр, фән-мәгариф үсеше буенча Россия Федерациясе төбәкләре арасында алдынгы сафта бара. Ул татар телен һәм мәдәниятен үстерүнең, татар халкының милли тәңгәллеген һәм бердәмлеген саклауның тарихи үзәгенә, ә меңьеллык башкалабыз Казан - татарларны үзенә тартып торучы милли-мәдәни үсеш мәркәзенә әверелде.

Зирәк Алмыш әмирнең, шигъри фәлсәфәче Кол Галинең, бөек вәгазьче һәм мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең, халык күңелен кузгаткан Габдулла Тукайның, кыю генерал Гани Сафиуллинның, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең һәм башка бик күп күренекле шәхесләрнең мәңгелек образлары - лаеклы үткәнебезнең символлары, хәзерге һәм киләчәк буыннарга рухи маяклар. Алар яшь варислар күңелендә ата-бабалары гамәлләре өчен горурлык хисләре тудыра, бүгенге көндә алар үрнәгендә үз халкыңа фидакарьләрчә хезмәт итү, үз киләчәгеңне, милләт киләчәген яхшыга үзгәртү мөмкинлеген күрсәтеп тора. «Мин татармын» -

татар халкының бай мәдәни тәҗрибәсеннән чыгып иҗади фикер йөртү формуласы ул.

**Замана таләпләре**

Бүген, гомуми глобальләшү, белемнәр чикләре җуелу һәм күчеш агымнары көчәю, тоташ бердәйлек һәм цифрлаштыру шартларында, үзгәрүчән дөньяда татар мәдәниятенең асылы турында мәсьәлә кузгала.

Татарларның, тарихи сәбәпләр аркасында, бөтен дөнья буйлап сибелеп яшәве үзен сиздерә. Кайбер территориаль һәм милли-дини төркемнәрнең аерылып чыгуга омтылышы күзәтелә. Җирле тәңгәллеккә генә басым ясалса, өстенлекле мәдәниятләрдә «эреп югалу» котылгысыз. Аерым бер урындагы сөйләм үзенчәлекләре һәм җирле гореф-гадәтләр белән мавыгу татар дөньясының бердәмлегенә зыян китерергә мөмкин. Мондый мәдәни-географик күптөрлелекне халкыбызның зур һәм уртак мөмкинлеге дип кабул итәргә кирәк. Җирле мәдәниятләр байлыгы, аларның туктаусыз бәйләнештә булуы яңа ачышларга, яңа мәгънәви төсмерләр тууга нигез булып тора.

Милли-территориаль оешмаларның зарурлыгын шик астына куярга маташучылар, милли тәңгәллек үсешен бары сәясәткә генә кайтарып калдыручылар, гадәттәгечә, аз түгел.

Мондый карашлар хәзерге заманга хас һәм алар дөньяның бик күп халыкларына кагыла. Әмма татарларның эчке көч-куәте зур, бу исә әлеге

таләпләрне үтеп чыга алмаслык киртәләр дип түгел, ә алга барганда исәпкә алынырга тиешле күренешләр дип кабул итәргә мөмкинлек бирә.

Эчке каршылыклар исә таләпләр күпкә катлаулырак. Кешенең үз шәхси каршылыкларын җиңүгә, милли хисләрне баетуга, ата-бабалардан калган барлык хәзинәне яңа мәгънәви төсмерләр белән тулыландыруга омтылыш мөһим. Милли мәдәниятнең халәте өчен киләчәк буыннар каршында һәрберебез җаваплы.

Елга үзенә инешләрне җыйган сыман, татар халкы да үзенең бай һәм катлаулы тарихы дәвамында Евразия киңлекләрендә таралып яшәүче төрле ыругларны һәм милли төркемнәрне акрынлап үзенә куша барган. «Бердәмлектә – көч» дигән татар халык мәкале бүген моңарчы булмаганча көнүзәк яңгырашка ия.

Җайлашучылыктан һәм битарафлыктан, «агым уңаена йөзүче» сүлпәнлектән арынырга вакыт. Үз халкыңның тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен һәм йолаларын өстән-өстән генә күзаллау, туган телне белүнең әһәмиятен бәяләп бетермәү кебек үк, котылгысыз рәвештә милли тамырларны югалтуга алып бара.

Татар халкының киләчәге безнең һәрберебездән, эчке максатларыбыздан, омтылышларыбыздан һәм гамәлләребездән тора. Гамәл стратегиясенең вазыйфасы - татар халкының үткәне, хәзергесе һәм киләчәге арасына күперләр салу.

## Стратегиянең максаты

Гамәл стратегиясе үзен татар дип танучы яисә татар халкына катнашы барлыгын тоючы кешеләрнең уртак мәнфәгатьләренә нигезләнә.

Гамәл стратегиясенең максатлары:

- татарларның киләчәккә планнар билгеләүдә бетмәс-төкәнмәс чыганак булган бай тарихи-мәдәни мирасы белән кызыксынуны көчәйтү;
- ата-бабаларның бөек казанышлары белән, үзеңнең шушы халыктан булуың белән горурлану хисенә ирешү;
- һәрбер татарның халкыбызның туган телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклауга һәм үстерүгә шәхси өлеш кертүе;
- татар халкының киләчәге хакына хәзерге заман каршылыкларын һәм хәвеф-хәтәрләрен җиңеп чыгу;
- татар халкын берләштерү, аның барлык халыклар арасында тулы хокуклы яшәешен тәэмин итү, мәдәни багланышларга һәм тирә-юньдәгеләрнең хасиятен һәм хисләрен ихтирам итүгә нигезләнеп тынычлык һәм татулык саклау.

## Милли үзаң

Татарларның үз-үзләрен тотышын, үзенчәлекле фикер сөрешен нигездә татар тарихының барышы һәм характеры билгеләгән. Милли холкыбызның ата-бабалар тәҗрибәсе тәрбияләгән иң яхшы чалымнары ireккә омтылуда, яңалыкка ачык булуда чагылыш тапкан. Чиксез киңлекләрне үзләштереп чыныккан татар холкы хәрәкәтчән-

лектән, аралаша һәм җайлаша белүдән, хезмәт сөючәнлектән һәм булдыклылыктан башка була алмый. Татар кешесе ачык йөзле һәм кунакчыл, төпле һәм үз карашларына тугрылыклы. Ата-бабаларның рухи горефләре әхлак, иман тудыра, өлкәннәргә карата ихтирам, сабырлык, вөҗданлылык һәм тыйнаклык, гаиләгә карата хасиятле мөнәсәбәт тәрбияли. Холкыбызның шушы үзенчәлекләре дөньядагы бөтен татарны берләштерә.

Татарларның милли тәңгәллеге асылында ни ята? Бу сорауга бары тик без генә – татарлар гына җавап бирә алабыз. Үз-үзеңне һәм үз йөрәгеңне тыңлый белергә генә кирәк.

Татар халкын берләштерү, татарларның тарихи-мәдәни бердәмлегенең фәлсәфи аңлатма бирү асылына төшенү, шулай ук гомумтатар мәдәни киңлек булдыру буенча мөһим адымнар XIX-XX гасырлар чигендә ясалган. Бу хәрәкәт татар милләтенең бердәмлеге, әдәби теленең уртаклыгы, татар халкына - мәгърифәт һәм алгарыш, татар мәдәниятенә - яңарыш зарурлыгы идеясенә нигезләнгән. Совет чоры, бер яктан, татар мәдәниятенең яңа рәвешләре барлыкка килүгә ярдәм итсә, икенче яктан, рухи кыйммәтләрнең беркадәр үзгәрүенә китерде.

Татарларның үзаңы милли рухка таяна, ә милли рух милли хисләрдә чагыла.

Глобальләшкән дөньяның күпаһәңле яңгырашында һәр татар газиз авазларны ишетеп алачак. Кемгәдер бу – бөек Габдулла Тукай дан җырлаган,

әнисенең бишек җыры, әби-бабаларының әкиятләре, әтисенең үгет-нәсихәте, мәктәп сабаклары аша күңеленә сеңгән туган тел. Кемнеңдер милли аңын ата-бабаларның көйгә салынган сагышы, халык җырларында сакланган моң уятып җибәрер. Ә кемдер шәһәр гөрелтесен ярып мөселманнарны намазга, дога кылырга өндәгән азан тавышын ишетеп үзенең татар икәнен тояр.

Дөньяның төрледән-төрле, чуар чагылышында татар үз җанына якын төсләрне күреп алачак – җете гөлләр һәм яшел үлән татар халкының бай бизәкләренә тыгыз үрелгән. Бу шатлыклы символларны милли киемнәрдә дә, татар өйләренең агачтан уелган бизәкләрендә дә, калфакларда һәм түбәтәйләрдә дә, атаклы читекләрдә дә, заманча нәкыш үрнәкләрендә дә күреп-танып алырга була. Алар татар осталары тарафыннан буыннан-буынга тапшырылганнар, бүген дә төрле заманнарны бәйләп торучы өзелмәс җеп хезмәтен үтиләр. Мәчет манаралары, татар авылларының яшеллеккә чумган басу капкалары яисә борынгы Болгар, Казан шәһәрләренең архитектура ядкәрләре – болар барысы да татар дөньясын танытучы сурәтләр.

Гаҗәп күптөрле затлы ашамлыклар арасыннан татар кешесе һәрвакыт үз милли ризыкларын сайлап алачак. Татар ризыгы өчен чикләр юк. Атаклы милли ризыклар бөтен дөньяны яулап алды инде. Токмачлы аш, бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, гөбәдия, чәк-чәк һәм башка шундый тәмле сыйлар

тезелгән бай табын, гадәттәге күчтәнәчләр – татар кунакчыллыгының нигезе, юмартлык, теләктәшлек һәм эчкерсезлек чагылышы. Үләннәр шифасын җыйган чәйнең һәм тәмле ризыкларның хуш исе туган йорт җылысын искә төшерә. Үзең дә сизмичә үз халкың ризыкларына үрелүең милли тәңгәллегеңә юл күрсәтәчәк.

Милли хисләр татарча кул бирүдә дә чагыла – аерым хөрмәт белән, туганнарча, татарча - ике куллап, чын йөрәктән күрешүдә. Бу гадәт татарларның теләктәшлеген, ихласлыгын күрсәтеп тора. Бу – бер-береңә ышанырга өндәү: без - намуслы кулдашлар, сезне учыбызны җәеп каршылыйбыз һәм үзара ихтирам өмет итәбез дигән сүз.

Милли хисләр татарларның тарихи тәҗрибәсенә төшенгәндә уяна. Ул хисләрне Казан Кремленең, Бөек Болгар, Биләр, Үкәк, Искер, Касыйм, Хаҗитархан, Сарай-Бату кебек урта гасыр шәһәрләренең, хан төрбәләренең, мәчетләрнең чал ташларына орынганда тоярга мөмкин.

Милли хисләрне ата-бабалар авазлары, халык риваятьләре, гаилә тарихлары һәм шәҗәрәләр уята. Өлкәннәргә хөрмәт – ул әле әрвахлар рухын олылау да, гаилә һәм халык гореф-гадәтләрен саклау да, үткәннәргә, мираска һәм туган җиргә сакчыл мөнәсәбәт тә. Үз нәселең истәлеге, үз Ватаныңа ихтирам, тарихи хәтер – болар нәсел көче чыганагы булган ата-бабалар белән бәйләнеш хисе, татар халкының куәте һәм бердәмлеге шарты. Башка

мәдәниятләргә карата ихтирам үз тамыр-ларыңа, үз-үзеңә хөрмәт аркылы туа.

Милли хисләрне югары тизлекле хәрәкәт, замана һәм уңыш артыннан куу, татарларның иҗтиһадлы егәре көчәйтә. Сулышларны кысучы ат чабышлары, җиңүгә ихтыяр көче, татарча очынып бию-бөтерелү, татарча йөгерек сөйләм, социаль хәрәкәтчәнлек, алгарышка омтылу – болар барысы да татарларда горурлык хисе уята.

Милли хисләр, ныклы калкан шикелле, татарларны рухи нигезләрен югалтудан сакларга сәләтле һәм сакларга тиеш, милли рухны ныгытырга тиеш.

Милли рух – ул һәр татардагы эчке «Мин». Аны татар халкының җиңүләре һәм уңышлары, иң күркәм гореф-гадәтләре, бай тарихы һәм мәдәнияте яшәтә. Аңа үзен һәм үз нәселен югары күтәрү түгел, камиллеккә омтылыш, үз хасиятен югалтмыйча, җитешсезлекләрен тану һәм аларны төзәтергә әзерлек хас.

Милли рух кайда яшәүләренә, туган телне белү-белмәүләренә, мөлкәтенә һәм вазыйфасына, дингә мөнәсәбәтенә яки нинди дин тотуына, карашларына һәм башка халәтләренә карамастан, барлык татарларның берләшүенә ярдәм итә. Татар кешесе үз халкы белән бер сулышта яши, башка халыклар белән дустанә һәм ихтирамлы мөнәсәбәттә тора.

Милли рух – татарның киләчәк буыннары өчен илһам, дөньякүләм уңышлар һәм яңа ачышлар чыганагы.

Татар булу – үзеңне татар дип хис итү ул.

Милли тәңгәллек фикерләр, хисләр һәм гамәлләр җыелмасында чагыла да инде. Шул ук вакытта татар халкының дөньяга карашы нигезләрендә нык торырга тырышу да гаять мөһим.

**Дөньяга караш нигезләре**

Татар халкының дөньяга карашы түбәндәге төшенчәләргә таяна: ата-бабалар истәлеге һәм шәҗәрә, туган тел, әхлак, иман, халык күңеле, моң, гаилә кыйммәтләре, гыйлем, мәгърифәт, хөррият һәм хәрәкәтчәнлек. Татар кешесенең милли асылы боларны кабул итү һәм боларга кушылу дәрәҗәсенә карап билгеләнә.

**Мәдәни мирасның кадерен белү һәм аны саклау**

Дөньяга карашның нечкәлеге һәм тирәнлеге мәдәни мирасның дөнья күләмендә танылган шедеврларында ачык чагылыш тапкан. Татар халкының иҗади башлангычы – илһам исә татарларны бертуктаусыз яңа, камилрәк рәвешләр эзләүгә рухландыра.

Иң киң мәгънәдә алганда, мәдәни хәзинә - татар халкының һәр кызының, һәр улының аңлы яшәеше нәтиҗәсе ул.

Галимнәр һәм энтузиастлар кадерләп җыйган һәм саклаган рухи һәм матди ядкәрләр замандашларны һәм киләчәк буыннарны татар тарихи-мәдәни мирасының иң яхшы үрнәкләре белән таныштыра.

Борынгы китап битләрендәге җетелеге уңган юллар, рухият турында, каһарманнарның фидакарь батырлыклары хакында телдән-телгә күчеп килгән риваятьләр, үткән заманнарның таш истәлекләре – болар барысы да мәдәният дигән симфониянең күркәм бүлекләре. Аңа үз ноталарыбызны кертү һәм балаларыбызны да шуңа тарту – һәрберебезнең әхлакый бурычы.

## Туган телне саклау

Тел - бөтен дөнья татарларының иң зур мәдәни байлыгы. Аның нигезендә туган татар мәдәнияте – театр, музыка сәнгате, сынлы сәнгать һәм башкалар рухи хәзинәләрне кабатлап-яңартып торырга һәм татарларның милли тәңгәллеген саклап калырга ярдәм итә.

Тел – тарихи мирасның ачкычы, мәдәни процессның өзлексезлеге һәм халыкның алга таба үсеше шарты. Аңа әхлакый кыйммәтләрне һәм дөньяга карашны тирәнтен аңларга мөмкинлек бирүче хәлиткеч мәгънә салынган. Безнең риваятьләр һәм хикәятләр, борынгы кулъязмалар һәм матур әдәбият әсәрләре, яраткан җырларыбыз һәм театр спектакльләре туган телебездә дөнья күрә. Язма телебез тарихының тамырлары бик тирән.

Татар теле – иң изге хисләребезне белдерергә ярдәм итүче остаз һәм дус. Хатирәләр, хатлар, берничә генә сүз язылган фоторәсемнәр – аерым кешенең бик кадерле шәхси ядкәре, шул ук вакытта, нәселенең һәм бөтен татар халкының

уртак тарихының бер кисәкчеге дә булып тора.

Төрки телләр гаиләсенә керүче татар теле, татарларга Евразиядә яшәүче башка бик күп тугандаш халыкларны тылмачсыз аңларга мөмкинлек биреп, мәдәният, фән һәм икътисад өлкәсендә хезмәттәшлек урнаштырырга булыша. Нәкъ менә татар теле бик озак еллар Россия һәм Үзәк Азия халыклары арасында дипломатия теле хезмәтен үтәгән. Моннан тыш, XX гасырга кадәр күп кенә мәгърифәтле татарлар гарәп, төрек, фарсы һәм башка телләрдә иркен сөйләшкән.

Татарларның гыйлемгә һәм алгарышка омтылышы хәзерге заманда да төрле телләр белүне шулай ук таләп итә. Татар халык мәкалендә әйтелгәнчә, «Телләр белгән – илләр белгән». Тизләнешле тормыш ритмыннан калышмыйча конкурентлыкка сәләтне саклап калу бары шул рәвешчә генә мөмкин.

## Мәсләк һәм иман кушканча эш итү

Татарларның тормыш юнәлешләрен һәм карашларын нигездә мәсләк һәм иман билгели. Аларның үзәгендә - өлкәннәргә ихтирам, шәфкать һәм үзара ярдәм, нык гаилә коруга омтылу, хәйриячелек традицияләрен дәвам итү кебек гомумкешелек кыйммәтләре. Болар балачактан тәрбияләнә, буыннан буынга тапшырыла.

Милләтне берләштерүдә, телне, мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне саклау һәм үстерүдә ата-бабаларыбыз 922 елда иректе һәм рәсми рәвештә кабул

иткән ислам дине гаять зур роль уйный. Хәнәфи мәзһәбенең әхлакый күрсәтмәләрен һәм рухи хәзинәләрен кабул итү төрле халыклар һәм диннәр белән күршеләрчә дус мөнәсәбәтләр корырга, татарларның күпмилләтле бергәлекләргә уңышлы кушылуына ярдәм иткән. Тарихи сәбәпләр аркасында татарларның бер өлеше православие динен тота. Татарлар дин тотучыга – димәк, ышанычлы кешегә һәрвакыт олы ихтирам белән караганнар.

Нәкъ менә мәсләк һәм иман кешегә терәк була, тормыш сынауларын җиңәргә көч бирә.

**Халык күңелен һәм моңын саклау**

Татар мәдәниятенең иң серле күренеше, аның иң югары чагылышы - моң. Моң – халык күңеленең, эчке гармониясенең үзенчәлекле синонимына әйләнгән күпкырлы төшенчә.

Әйтеп аңлатып булмый торган әлеге хискә һәр татар җанында урын бар. Халык күңеле, уртак кичерешләр, эчке гармония – барысы да «моң» төшенчәсенең төрле төсмерләре. Татар халкының бөтен тәҗрибәсе, күп буыннарның рухи кичерешләре шушы бер сүздә чагылыш тапкан. Үзеңдә моң тәрбияләп буламы? Аны ничек табарга? Бу сорауларга йөрәк җавап бирер.

Үзенчәлекле татар моңы мәдәни күптөрлелек җирлегендә кешенең эчке матурлыгын, ниятләре сафлыгын, максатлары игелеген ачып бирә. Җанга якын халык көйләрен, Илһам Шакировның гаҗәеп тавышын һәм заманча җырларны татарның мәшһүр пентатоникасы берләштерә.

## Гадәти гаилә кыйммәтләренә иярү

Өлкәннәргә карата һичсүзсез ихтирам, сабыйларны ихлас ярату һәм тату гаилә төзү – татарларның яшәеш таләбе. Туганлык дәрәҗәсе үзенчәлекләре – ерак һәм якын туганлык - татарлар өчен шартлы нәрсәләр. Нәселнең барлык әгъзалары да – туганнар. Бер-берең өчен җаваплылыкны һәм үзара ярдәмләшүне якын кешеңә карата изге бурыч итеп аңлау шуннан килә.

Гаилә бәйләнешләренең ныклыгы гореф-гадәтләр ныклыгын да билгели. Өлкәннәрнең шәхси үрнәге – үсеп килүче буын өчен иң күркәм тормыш сабагы ул.

Аерым шәхесләрнең, гаиләнең тормыш юлы һәм халыкның күпгасырлык үткәне - кеше үзаңына йогынты ясаучы мөһим факторлар. Күп кенә гаиләләр үз шәҗәрәләрен тиңсез ядкәр итеп саклыйлар. Шәҗәрә - элеккеге буыннарга ихтирам билгесе, ул үзеңнең тарихи тамырларыңны аңларга ярдәм итә.

Бөек тарихи вакыйгаларга катнашың булу, Ватанга һәм үз халкың мәдәниятенә берсүзсез мәхәббәт – болар һәр кешегә бу дөньяда «үзен табарга», үзенең татар дөньясыннан булуын һәм милләтенә тугрылыгын белдерергә мөмкинлек бирүче ныклы нигез.

Россиянең һәм дөньяның чиксез киңлекләренә таралып яшәгән миллионлаган татар кешесе олы татар гаиләсенең бер өлеше булып тора. Туган туфрак җылысы, ата-ана мәхәббәте һәм борынгы

риваятьләр – тумыштан килгән әлеге җуелмас хәзинәләребез гомер буе янәшәбездә.

**Мәгърифәткә омтылу**

Белем кадерен белү, китапка һәм укымышлы кешеләргә хөрмәт белән карау, гыйлемгә тартылу татарларга һәрчак хас булган. Татарлар гасырлар буе Урта Азиянең, Мисырның, Якын Көнчыгышның, Көнбатыш Европаның иң яхшы белем үзәкләрендә укырга омтылган. Курсави, Ялчыгол, Утыз-Имәни, Мәрҗани, Баруди, Бигиев һәм башка күренекле фикер ияләре чит илдә алынган белемнәрен эшкәртеп, җирле шартларга җайлаштырганнар.

Гарәп-мөселман традицияләренең Европадагы яңарышы идеяләре белән кушылмасы татар фәлсәфи фикере феномены тудырган. Ул XIX - XX гасырлар чигендә бөтен мөселман дөньясы өчен маякка әверелгән. Идел-Урал төбәгендәге «Мөхәммәдия», «Буби», «Хөсәения», «Галия» һәм башка мәдрәсәләр зур белем үзәкләренә әверелгәннәр, алар Россия империясенең төрле почмакларыннан һәм башка дәүләтләрдән күпсанлы шәкертләрне үзләренә җәлеп иткәннәр.

Әлеге уку йортларында әзерләнгән белгечләр соңыннан совет мәгариф системасының нигезен тәшкил итеп, дөньяга бик күп күренекле фән һәм сәнгать, сәясәт эшлеклеләрен тәрбияләгән, ТАССР-да мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында белем бирүне оештыруда, башка илләрдә милли зыялы-

лар катлавын булдыруда әһәмиятле роль уйнаган.

Татар мәгърифәтчесе Ризаэтдин Фәхретдин: «Һәрбер кеше вә һәрбер кавем вә милләтнең бәхетле булуларына баш сәбәп – гыйлемдер», – дип язган. Белемгә омтылыш, дөньядагы үзгәрешләргә тиз төшенүчәнлек, фән-техника казанышларын иҗади куллану сәләте – татарларга хас сыйфатларга әйләнгән.

**Хәрәкәтчәнлек һәм ирекле үсеш**

Күчмә һәм утрак мәдәниятләр кушылмасы татарларның чынбарлыкка җайлашу дәрәҗәсен билгеләгән, бөтен яңа нәрсәне үзләштерү сәләтенә җирлек тудырган.

Татарларга элек-электән үк даими хәрәкәт, алда торган мәсьәләләрне тиз һәм җәһәт хәл итәргә омтылу хас. Ата-бабаларыбыз Алтын Урда чорында ук кыйтгаларның чиксез киңлекләрен үз ватаннары дип санаганнар, алар буйлап сугыш һәм сәүдә максатларында ансат кына күченеп йөргәннәр.

Татарлар өчен азатлык дигән күпкырлы төшенчә зур әһәмияткә ия. Ирек, азатлык, хөррият – барысы да азатлык турында. Үз сәләтләреңне гамәлгә ашыру иреге, үз фикереңне белдерү иреге, үз тарихыңны, үз язмышыңны үзең язу иреге.

Инде Яңа заманда алдан күрүчән татар сәүдәгәрләре Европага да, Казахстан далаларына да, Кытай чикләренә яисә Урта Азиянең кайнар чүлләренә дә тиз генә барып чыга алганнар. Алар Россия базарларын Көнчыгыш базарларына сәүдә җепләре

белән бәйләп, икътисади һәм мәдәни йогынтыларын киңәйтә барганнар.

## Татар булу

Миллилекнең яңа мөмкинлекләрен эзләү – һәрберебезнең бурычы. Татар мәдәнияте һәрвакыт күп төрле булуы белән аерылып торган һәм шуңа күрә төрле үзгәрешләр чорында тотрыклыгын югалтмаган. Безне бөек гамәлләргә омтылу һәм үз көчебезгә ышану берләштерә. Без төрле-төрле, әмма безнең рухи хәзинәләребез уртак.

Татар булу ул:

– рухи хәзинәләребез белән уртаклашу һәм аларны баету;

- кайда яшәүләренә, нинди телдә сөйләшүләренә, нинди дин тотуларына карамастан, барлык татарлар белән бердәмлекне ныгыту;

- татар дөньясының бай тарихи-мәдәни мирасы белән горурлану һәм үз халкың тарихын өйрәнүгә, телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен үстерүгә омтылу;

- белемгә, алгарышка омтылу, үз эшеңә иҗади караш, шул рәвешчә халкыбызның мәдәни һәм акыл мөмкинлекләрен арттыру;

- ватанпәрвәр булу, Ватанны ныгыту;

- барлык халыклар бергәлегендә татарларның тулы хокуклы яшәешен тәэмин итү, тынычлык һәм татулык саклау;

- заманнан калышмыйча, югары тизлектә бару, нинди генә сынаулар булмасын, ияр өстендә калырга, егылмаска, имгәнмәскә тырышу, һәм,

ахыр чиктә, максатка ирешү.

Мәдәниятебез, телебез өчен, гореф-гадәтләребезне саклау өчен, үзебезгә, ата-бабаларыбызга кадерле хәзинәләрне киләсе буыннарга тапшыру өчен җаваплылыкны бары без генә үз өстебезгә ала алабыз.

Без үз киләчәгебезне үзебез төзибез. Татар мәдәниятенең ни белән дан казаначагы, балаларыбызның бездән нинди сабак алачагы безнең һәрберебездән тора. Безнең уртак рухи хәзинәләр кыю тәҗрибәләр ясауда, уңышларга ирешүдә таянычыбыз һәм көч алу җирлеге булып тора. Рухи хәзинәләребез – илһам чыганагы, милләтне яңарту, яңа үсеш офыклары ачу өчен бетмәс-төкәнмәс байлык. Иң мөһиме – үз халкың хакына аңлы гамәлләр кылу һәм аңа хезмәт итү.

## Гамәл стратегиясен тормышка ашыру буенча эшчәнлекнең төп юнәлешләре

Милләт Җыены тарафыннан кабул ителгән Гамәл стратегиясенә таянып, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның «Татарлар: гореф-гадәтләргә тугрылык, киләчәккә ышаныч» («Татары: верность традициям, уверенность в будущем») дигән мәкаләсе нигезләмәләрен истә тотып, аларның эшчәнлек юнәлешенә омтылышын игътибарга алып, «Бөтендөнья татар конгрессы» Халыкара Берлеге һәм аңа кергән оешмалар Стратегияне гамәлгә ашыру эшенә татар җәмәгатьчелеген актив җәлеп итү максатыннан үзләре өчен түбәндәге төп эшчәнлек юнәлешләрен билгеләде:

*Оештыру эше*

- төбәкләрдә татар иҗтимагый оешмалары вәкилләрен берләштерүче шуралар (советлар) төзүнең максатчанлыгын билгеләү;
- татарлар күпләп яшәгән төбәкләрнең территориаль милли-мәдәни оешмалары арасында үзара бәйләнешне ныгыту;
- уртак мәдәни кыйммәтләргә нигезендә татар дөньясының бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү;
- татарларның башка халык вәкилләре белән дустанә-тату мөнәсәбәтләрдә яшәүләрен тәэмин итү;
- Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм чит

илләр киңлекләрендә Татар мәдәнияте көннәрен оештыру һәм уздыру;

- ел саен уздырылып килә торган «Милли тормыш һәм дин» Бөтенроссия татар дин әһелләре форумын уздыру;
- татар милли-мәдәни оешмалары эшчәнлеген оештыруның актуаль мәсьәләләренә кагылышлы белем бирү дәресләре, семинарлар, лекцияләр үткәрү;
- татар халкының телен, мәдәниятен һәм милли гореф-гадәтләрен саклау эшчәнлеге буенча төбәк оешмалары тәҗрибәсен өйрәнү, гомумиләштерү һәм киң җәмәгатьчелеккә тарату;
- төбәкләрдә татар иҗтимагый оешмаларының активлыгын һәм мөстәкыйльлеген арттыру өчен кызыксындыргыч чаралар күрү;
- Интернет киңлекләрендә «Дөнья татарлары» челтәре берләшмәләрен үстерүгә ярдәм итү һәм аларны даими рәвештә яңа мәгълүмат белән тулыландыру;
- төбәк һәм җирле иҗтимагый һәм мәдәниагарту оешмаларының, аларның актив хезмәткәрләре эшчәнлеген чагылдыручы мәгълүмати һәм методик материаллар әзерләү;
- «Туган җир» журналында һәм «Татарлар» газетасында бастыру өчен «Бөтендөнья татар конгрессы» Халыкара Берлегенә керүче оешмаларның эшчәнлеге турында материаллар әзерләү;

- татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә татар ашларын, кием-салымнарын һәм традицион спорт уеннарын популярлаштыру;
- татар милли бәйрәмнәрен уздыруда, Россия Федерациясе төбәкләреннән һәм якын чит илләрдән килгән режиссерларны һәм бәйрәм оештыручыларны укытуда, махсус күнекмәләр алуда ярдәм күрсәтү;
- татар иҗтимагый оешмаларына Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе грантларын алу өчен проектларны булдыруда ярдәм итү һәм аларны гамәлгә ашыруда катнашу;
- ел саен үткәрелеп килүче «Татар халкының этнографик мозаикасы» фотоконкурсын үткәрү, аның нәтиҗәләренә нигезләнеп, күргәзмә оештыру;
- татарлар яшәгән урыннарда татар мәдәниятенең җирле үзенчәлеген саклап калуга юнәлдерелгән проектлар булдыру һәм оештыру, методик һәм башка ысуллар белән гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү.

*<u>Татар телен саклау һәм үстерү</u>*

- татар мәгариф оешмалары (балалар бакчалары яки аларда татар төркемнәре, мәктәпләр, якшәмбе мәктәпләре h.б.) ачу (эшчәнлеген җайга салу) өчен максатчан рәвештә ата-аналар белән эшләү, татар теле һәм әдәбияты укытучыларын, өстәмә белем бирү мөгаллимнәрен сайлап алуда ярдәм итү;

- Россия Федерациясе төбәкләрендә урнашкан татар телен өйрәнүче һәм татар телендә белем бирүче гомуми белем бирү оешмаларын татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре, уку әсбаплары белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү;
- татар теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләү өчен сәләтле яшьләрне сайлап алу һәм Татарстан Республикасында урнашкан югары уку йортларында белем алырга юнәлеш бирү;
- Бөтенроссия татар теле укытучылары җыены өчен делегатлар сайлап алуда һәм юллауда катнашу;
- ел саен үткәрелеп килүче «Татарча диктант» акциясендә татарларның катнашуын оештыру;
- үсеп килүче буын һәм яшьләр арасында «Татар иле» электрон мәктәп энциклопедиясе» мәгариф басмасының электрон ресурсын популярлаштыру;
- татар халкы күпләп яшәгән урыннарда җирле чаралар үткәрү вакытында татар телен куллану даирәсен киңәйтү;
- җирле мөселман дини оешмаларына татар телендә вәгазьләр әзерләү эшендә ярдәм күрсәтү;
- «Ана теле» татар телен дистанцион өйрәнү онлайн-мәктәбен куллану һәм аның кулланылыш даирәсен киңәйтү;
- татар телендә радио һәм телевидение эшчәнлеген популярлаштыру, татарлар күпләп яши торган урыннарда халыкның яшәешен чагылдырган сюжетлар әзерләү.

*Мәдәни мирасны ачыклау, саклау һәм баету*

- татар халкының телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклап калу һәм үстерү эшенә теләгән һәркемгә үзеннән шәхси өлеш кертергә мөмкинлек бирүче проектлар башлап җибәрү;
- халык тарихы һәм мәдәнияте белән бәйле тарихи урыннарны һәм объектларны билгеләү, аларны саклау һәм мәңгеләштерү буенча тәкъдимнәр булдыру;
- Россия Федерациясе киңлекләрендә һәм дөньяның башка илләрендә татар халкының истәлекле урыннары җыелмасын (базасын) әзерләү;
- татарлар яшәгән торак пунктларның тарихын чагылдыручы җыентыклар һәм аерым басмалар әзерләү һәм аларны фәнни яктан эшкәртү;
- «Архивларда татар тарихына кагылышлы документлар» («Документы по истории татар в архивохранилищах») фәнни җыентыклары өчен материаллар әзерләү;
- һәр ел татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр форумын уздыру;
- Бөтендөнья татар галимнәре форумын үткәрү;
- татарлар күпләп яши торган төбәкләрдә татар тарихына караган экспозицияләр белән музей мәйданчыклары булдыру эшенә нигез салу (мәктәпләрдә, мәдәният йортларында, мәчетләрдә һ.б.);
- тарихи һәм мәдәни мирас объектларында тукталышлар ниятләп, татар торак пунктлары

буенча туристик маршрутлар оештыру, тиешле экспозицияләр булдыру;
- мәшһүр татар шәхесләре турында брошюралар чыгару өчен материаллар әзерләү;
- татар халкының тарихи-мәдәни мирасын популярлаштыру.

*<u>Яшьләр белән эшләү</u>*
- татарларның бай тарихи-мәдәни мирасы белән кызыксынуны арттыруга юнәлдерелгән проектлар булдыру һәм тормышка ашыру;
- яшьләрнең замана таләпләренә туры килердәй сыйфатлы белем алырга омтылышларын хуплау, бу юнәлештә ярдәм күрсәтү;
- Халыкара татар яшьләре форумнарын үткәрү;
- ел саен үткәрелә торган Татар яшьләре көннәрен уздыру;
- Бөтендөнья татар яшьләре форумына ШТК (КВН) проектын тормышка ашыруда ярдәм күрсәтү;
- ел саен уздырылып килүче «Печән базары» фестивален оештыру һәм үткәрү;
- ел саен уздырылып килүче «Jadidfest» шәһәр мәдәнияте фестивален оештыру һәм үткәрү;
- ел саен уздырылып килүче «Татар кызы» Бөтенроссия бәйрәмен үткәрү;
- ел саен уздырылып килүче «Җәлил укулары» Халыкара әдәби шигырь укучылар конкурсында балалар һәм яшьләрнең катнашуын оештыру;
- Бөтендөнья татар яшьләре форумына «Ачык

университет» белем бирү проектын тормышка ашыруда ярдәм итү;

- татар халкының мәдәни мирасын саклау, аның заманча формаларын кертү буенча яшьләрнең инициативаларын һәм проектларын яклау.

*Татарлар арасында эшлекле активлыкка ярдәм күрсәтү*

- ел саен уздырылып килүче Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыеннарын оештыру;
- ел саен уздырылып килүче «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумын оештыру;
- эшкуарлык җәмәгатьчелеге вәкилләрен татар телен, мәдәниятен һәм халыкның гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү буенча актив иҗтимагый эшчәнлеккә җәлеп итү;
- татар эшмәкәрләренең төбәкара хезмәттәшлегенә ярдәм күрсәтү;
- татар халкы күпләп яши торган урыннарда кече һәм урта бизнеска, иҗтимагый бизнес һәм җитештерү эшен оештыруның гаилә формаларына ярдәм итү һәм популярлаштыру;
- эшмәкәрләр арасында хәйриячелекне үстерү: кече ватанга, туган якларга, мәхәлләләргә ярдәм күрсәтүне популярлаштыру.

*Гаилә кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту*

- гаилә шәҗәрәләре булдыру буенча халык

белән эшне оештыру, аларның нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә популярлаштыру;

- «Минем шәҗәрәм» («Шәҗәрә – Моя родословная») Бөтенроссия фестиваль-бәйгесендә катнашу өчен иң яхшы проектларны сайлап алу һәм тәкъдир итү;
- гаилә кыйммәтләрен популярлаштыруга юнәлдерелгән чаралар әзерләү һәм оештыру;
- «Пар канатлар» татар гаиләләре җыенында катнашу өчен иң яхшы татар гаиләләрен ачыклау һәм тәкъдим итү;
- үсеп килүче буынны татар этнопедагогикасы традицияләрен исәпкә алып тәрбияләүнең актуаль мәсьәләләре буенча төбәк һәм җирле челтәр ресурсларын булдыру һәм уңышлы эшчәнлеген тәэмин итү;
- татар яшәү рәвешен популярлаштыру өчен багланышлы челтәр мәйданчыклары, аралашу берлекләре, үзара ярдәм күрсәтү оешмалары булдыру;
- татар туйларын, исем кушу мәҗлесләрен һ.б. әзерләү һәм үткәрү йолаларын популярлаштыру;
- яшь буынны үз халкының бай тарихи-мәдәни мирасы, аның данлы традицияләрен дәвам итүчеләр, туган җир милләтпәрвәрләре һәм Ватанны саклаучылар рухында тәрбияләү;
- балаларда, татар халкының дөньяга карашына нигезләнеп, милли рух формалаштыру.

*Халык иҗаты эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү*

- татарлар күпләп яшәгән урыннарда татар фольклор һәм үзешчән театр коллективларын булдыру һәм аларның эшчәнлегендә ярдәм күрсәтү;
- татар рәссамнарына, дизайнерларга, модельерларга, һөнәрчеләргә ярдәм итү һәм аларның күргәзмә проектларын оештыру;
- милли костюмнар һәм милли музыка уен кораллары комплектларын эшләүдә һәм әзерләүдә ярдәм күрсәтү;
- ел саен уздырылып килүче «Түгәрәк уен» төбәкара фестивалендә катнашуны оештыру;
- «Идел-йорт» төбәкара конкурсын уздыруга ярдәм күрсәтү һәм анда театр коллективларының катнашуын тәэмин итү;
- милли әдәбият, сынлы сәнгать, кино, архитектура һ.б. өлкәләрдә сәләтләрне барлау һәм аларның эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү;
- татар музыкасы фестивальләрен, сынлы сәнгать күргәзмәләрен һ.б. оештыру;
- И. Шакиров исемендәге «Татар моңы» фестивален әзерләү һәм оештыру.

Әлеге исемлек тулы җыелма түгел. Һәр татар кешесенә, һәр татар иҗтимагый оешмасына бирегә үзеннән өлеш кертү өчен мөмкинлекләр ачык.

Бары без, үзебез, бары уртак көчләр белән генә бу Стратегиядә бәян ителгән гамәлләрне тормышка ашыра алабыз.

Бүгенге тормышыбыз да, киләчәгебез дә безнең

һәрберебезгә, һәр оешмабызга бәйле.

Без дөньяның күпсанлы илләрендә, тарихи ватаныбызның – Россиянең – барлык төбәкләрендә диярлек яшибез. Шул сәбәпле без төрле. Алга таба башка халыклар белән хезмәттәшлек юлында үсеш өчен нәкъ менә безнең күптөрлелегебездә милләтнең потенциалы бик зур. Һәркем белән дустанә-тату мөнәсәбәтләрдә яшәү, туган җиребезнең чын патриотлары булу һәм Ватаныбызны ныгыту – бу юнәлеш өчен иң мөһим шартлар.

Гамәлләр стратегиясендә бәян ителгәнчә, халкыбызның киләчәге турыдан-туры безнең һәрберебезнең алга барырга әзерлегенә бәйле. Милләтебезне даими яңарту нигезендә безнең милли рухыбыз, безнең өзелмәс кыйммәтләребез ята.

Үзеңнең асылыңның татар булуын аңлау, тану, замана һәм аның үзенчәлекләренә туры китереп, үз халкыңа тугъры хезмәт итә белү бик мөһим.

**2020 елның 29 августында**

**Милләт Җыены тарафыннан расланды**

**ФИКЕР ҺӘМ ТӘКЪДИМНӘР ӨЧЕН**

420060, Татарстан Республикасы,

Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты

e-mail: tatar-strategiya@mail.ru

*Бөтендөнья татар конгрессының рәсми сайты:*

http://tatar-congress.org

*Без социаль челтәрләрдә:*

https://www.instagram.com/tatarcongress

https://vk.com/tatarcongress

https://www.facebook.com/tatarcongress

https://twitter.com/tatarcongress

https://ok.ru/tatarcongress

# ТӘКЪДИМНӘР ҺӘМ ИСКӘРМӘЛӘР ӨЧЕН

# ТӘКЪДИМНӘР ҺӘМ ИСКӘРМӘЛӘР ӨЧЕН

# ТӘКЪДИМНӘР ҺӘМ ИСКӘРМӘЛӘР ӨЧЕН